ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ютазинская, д.14А,
с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ютазы урамы, 14А йорты,
Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 2-44-11, факс:2-44-13, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№3 «13» февраль 2023 ел

Бәйрәкә авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында»гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

2022 елның 27 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында халык җыенының 13 санлы карарларын гамәлгә ашыру максатларында,

Бәйрәкә авыл җирлеге Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Бәйрәкә авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина

Бәйрәкә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 13 февраленен 3 санлы карарына 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Бәйрәкә авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар, гражданнар җыенында катнашу-катнашмауларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2023 елның 9 гыйнварыннан 2023 елның 20 мартына кадәр үзара салым акчалары түләүне башкарыла.

3. Җитди сәбәпләр булган очракта, ә аларга түбәндәгеләр керә ала:

а) торган урын буенча озак яшәмәү,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук имзаны тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Бәйрәкә авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салымы акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Бәйрәкә авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2023 елның 13
февраленен 3 санлы карарына
2 кушымта

Бәйрәкә авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
____ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адрес: ________________________________________________________________
Халык җыены карары нигезендә торак пунктта_____________________Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге 2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча сезгә __________ _ _ _ _ кадәр халык җыены чараларын тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләүне түбәндәге реквизитлар буенча башкарырга кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО

Билгеләнгән түләү 2023 ел өчен Бәйрәкә авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы.

Җитәкче ______________________________________________________
М.У. (имза) (имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Бәйрәкә авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ __________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(муниципаль берәмлек исеме)
_________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адрес: _____________________________________________________________
«__» ________________ 20__ елны __________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм Бәйрәкә авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*